Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл Советы
КАРАРЫ

18 ноябрь 2020 ел № 6

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2019 елның 18 декабрь 121 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Ачыклау тәртибендә

Яңа Никольский авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2019 елның 18 декабрь 121 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

1.1.1. 2 бүлекнең 2.1 пунктында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль-мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.1.2 3 бүлекнең 3.1. пунктын төшереп калдырырга;

1.1.3 3 бүлекнең 3.2 пунктында "Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы" сүзләрен төшереп калдырырга»;

1.1.4 Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 2 һәм 3 пунктларында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль-мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.1.5 Нигезләмәгә 2 кушымтаның 1 бүлеге 1.1 пунктында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль-мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә

алмаштырырга.»;

1.1.6 Килешүгә 1 нче кушымтада «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль-мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга.»;

2. Әлеге карарны Яңа Никольск авылы, Үзәк урам, 100 нче йорт; Салкын Алан авылы, Луговая урамы, 60 нчы йорт; Иштирәк авылы, Чишмә урамы, 3 нче йорт; Хазовка, Болтаево, Завод, Кәминкә, Кече Шуган, Поташная Поляна, Сосновка бистәләре территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә торуны Яңа Никольский авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Яңа Никольский
выл җирлеге Башлыгы Кәримова Г.А.